Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Данауровка авыл җирлеге Советы

КАРАР

6 нчы март 2024 ел № 46/1

Татарстан Республикасы Чистай
муниципаль районы Данауровка
авыл җирлеге Советының«Чистай
муниципаль районы» Данауровка
авыл җирлеге»муниципаль
берәмлеген төзекләндерү
кагыйдәләрен раслау турында"
19.07.2013 елгы 6/2 нче номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Чистай муниципаль районының «Данауровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлеге Советының 19.07.2013 елның, 6/2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының "Данауровка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: :
1.1. 5 нче пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

"Сосновский балтырганы - эре үләнле үсемлек, зонтлылыр гаиләсенә караган борщевик нәселе төре. Үсемлек озак вакыт төзәлми торган көчле пешүләр китереп чыгару сәләтенә ия;

гербицидлар-үсемлекләрне юк итү өчен кулланыла торган химик матдәләр.»;

1.2. 8 нче пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:
“Җир кишәрлекләренең ияләре Сосновский балтырганын үз милкендәге, хуҗалыгындагы яки файдалануындагы җир кишәрлекләреннән алып ташлау буенча чаралар үткәрергә тиеш.

Сосновский балтырганын бетерү буенча чаралар чәчәк ату башланганчы, гербицидлар һәм (яки) арборицидлар белән үсентеләрене сиптерү; коры үсемлекләрне кисү, җыю, тамыр системасын казу; туфрак эшкәртү, күпьеллык үләннәр чәчү юлы белән үткәрелергә тиеш.

Язгы-җәйге чорда Сосновский балтырганы белән көрәшкә юнәлдерелгән чаралар үткәрергә кирәк. Сосновский балтырганының биологик үзенчәлеген исәпкә алып, аның белән көрәш стратегиясе беренче чиратта аның орлыгы барлыкка килүенә юл куймауга юнәлдерелгән булырга тиеш. Үлән чабуны берничә ел рәттән сезонга өч тапкыр үткәрергә кирәк. Беренче чабуның оптималь вакыты-бутонлашу фазасы яки чәчәк ату башы, аннан соңгылары балтырган үскән саен үткәрелә. Сосновский балтырганын чабу аның таралу темпларын киметергә мөмкинлек бирә, әмма, кагыйдә буларак, үсемлекләрнең үлеменә китерми. Аны кечкенә участокларда юк итү өчен, аның үсешенең беренче фазаларында тамыр белән казып чыгарырга кирәк. Бу эшләр тыгыз бияләйләрдә һәм саклагыч киемдә башкарылырга тиеш. Яфраклар коелган вакытта – коелган яфракларны җыю һәм чыгару тәүлегенә бер тапкыр.».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында яки Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә (бастырып чыгарырга) (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән (бастырылган) көннән үз көченә керә.

Данауровка авыл җирлеге
башлыгы Сашин А.В.